**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы мунципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Ак-Чишмә торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**22.11.2022 ел** **№ 4**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегененә керүче Ак-Чишмә торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Ак-Чишмә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Ак-Чишмә торак пунктында зират территориясен киртәләүне ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

-Ак-Чишмә торак пунктында Бөек Ватан сугышында катнашучылар истәлегенә мемориаль такта әзерләү һәм урнаштыру (проект төзү, проект төзү хезмәте күрсәтү, төзелеш материаллары һәм җиһазлары сатып алу, нигез салу җайланмасы, мемориал сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Ак-Чишмә торак пунктында җирлек эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев